РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 19 » 02 2021 ел №105

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү белән бәйле мәсьәләләрне карау буенча ведомствоара комиссия төзү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт социаль ярдәме турында» 1999 елның 17 июлендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясенең «Гражданнарга социаль ярдәм» дәүләт программасын раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 15 апрелендәге 296 номерлы карары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, “Татарстан Республикасында дәүләт социаль ярдәме күрсәтү турында, шул исәптән социаль контракт нигезендә» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 02.09.2014 № 635 карары, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Советының 2020 елның 28 апрелендәге 18 номерлы карары белән кабул ителгән "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты турында 2006 елның 12 гыйнварындагы 1 номерлы карары белән расланган Нигезләмә нигезендә, шулай ук авыр тормыш хәлендә калган затларга социаль ярдәмнең адреслы рәвешләренең нәтиҗәлелеген арттыру максатларында Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтүгә бәйле

мәсьәләләрне карау буенча ведомствоара комиссия составын расларга (1 нче кушымта).

2. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтүгә бәйле мәсьәләләрне карау буенча Ведомствоара комиссия турында Нигезләмәне расларга (2 нче кушымта).

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://yutazy.ru адресы буенча (Интернет челтәре басмасы сыйфатында теркәү: 07.12.2011 ел, ЭЛ № ФС 77-47613), Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары С.А. Рузановка йөкләргә.

Татарстан Республикасы Ютазы
муниципаль районы Башкарма
комитеты җитәкчесе С.П. Самонина

Р. М. Якупов
2-74-14

Кушымта №1
Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты Карарына

___ 2020 ел №___

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтүгә бәйле мәсьәләләрне карау буенча ведомствоара комиссия составы

- Рузанов С.А. - Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары, рәис;
- Рәшитова З.Ә. - Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Ютазы муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге начальнигы, рәис урынбасары (килешү буенча);
- Хисмәтуллина З.Р. - Ютазы муниципаль районында «Гармония» халыкка комплекслы социаль хезмәт күрсәтү үзәгенең социаль эш буенча белгече, комиссия секретаре (килешү буенча).

Комиссия әгъзалары:
- Борисов А.В. - Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы (килешү буенча);
- Галиәхмәтова Г.А. - Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Ютазы муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге консультанты (килешү буенча);
-Магамедова А.М. - Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге начальнигы;
- Миңневәлиев Н.Н. - Ютазы муниципаль районында «Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУ директоры (килешү буенча);
- Мөхәммәтов С.М. - Ютазы муниципаль районында «Гармония» халыкка социаль хезмәт күрсәтүнең комплекслы үзәге директоры (килешү буенча);
-Звягинцева Е.В. - Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының Ютазы муниципаль районындагы Эшкуарлыкка ярдәм фондының төбәк вәкиле (килешү буенча);
- Якупов Р.М. - Татарстан Республикасы Ютазы район Советының юридик бүлеге начальнигы (килешү буенча).

Кушымта №2
Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты Карарына

___ 2020 ел №___

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтүгә бәйле мәсьәләләрне карау буенча ведомствоара комиссия турында нигезләмә

## 1. Гомуми нигезләмә

1.1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтүгә бәйле мәсьәләләрне карау буенча ведомствоара комиссия (алга таба - Ведомствоара комиссия) Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү мәсьәләләрен карау өчен Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты каршында төзелде.

1.2. Ведомствоара комиссия үз эшчәнлегендә «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт социаль ярдәме турында» 1999 елның 17 июлендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон, «Гражданнарга социаль ярдәм» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 15 апрелендәге 296 номерлы карары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, “Татарстан Республикасында дәүләт социаль ярдәме күрсәтү турында, шул исәптән социаль контракт нигезендә» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 02.09.2014 № 635 карары, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Советының 2020 елның 28 апрелендәге 18 номерлы карары белән кабул ителгән "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты турында 2006 елның 12 гыйнварындагы 1 номерлы карары белән расланган Нигезләмәгә һәм әлеге нигезләмәгә таяна.

1.3. Ведомствоара комиссия составы Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторы, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Ютазы муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге, «Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУ, Ютазы муниципаль районында «Гармония» комплекслы үзәге дәүләт бюджет учреждениесе, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу үзәк район хастаханәсе» ДАССУ, Ютазы район Советы хезмәткәрләре арасыннан төзелә.

Ведомствоара комиссия әгъзалары саны кимендә 5 кеше булырга тиеш.

## 2. Комиссиянең функцияләре һәм вәкаләтләре

2.1. Ведомствоара комиссия Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Ютазы муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге тәкъдим иткән гаризаларны һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында авыр тормыш хәлендә калган затларга социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү турындагы документларны карый, Татарстан Республикасының Ютазы муниципаль районындагы социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү турында карар кабул итә.

2.2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Ютазы муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге тарафыннан тапшырылган гаризаларга һәм дәүләт социаль ярдәме күрсәтү турындагы документларга өстәмә тикшерү уздыру кирәк булганда, шулай ук әлеге Нигезләмәнең 1.2 пунктында санап үтелгән хокукый актларда билгеләнгән очракларда, ведомствоара комиссия авыр тормыш хәлендә калган затларның яшәү шартларын комиссияләр тикшерүен уздыруны билгели, аның нәтиҗәләре буенча ведомствоара комиссия акт рәсмиләштерә.

## 3. Ведомствоара комиссиянең эш тәртибе

3.1. Ведомствоара комиссия утырышы кирәк булган саен уздырыла.

3.2. Ведомствоара комиссия эшен аның рәисе алып бара. Рәис булмаганда, ведомствоара комиссия утырышын аның урынбасары үткәрә.

3.3. Комиссия утырышы, әгәр анда ведомствоара комиссия әгъзаларының кимендә яртысы катнашса, тулы хокуклы. Карар ведомствоара комиссия әгъзаларыннан күпчелек тавыш белән кабул

ителә. Тавышлар тигез булган очракта, хәлиткеч булып ведомствоара комиссия рәисе тавышы тора. Ведомствоара комиссия карары беркетмә рәвешендә рәсмиләштерелә, аңа ведомствоара комиссиянең барлык шунда катнашучы әгъзалары имза сала. Ведомствоара комиссия утырышына Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районындагы социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү турында гаризалар һәм документлар буенча аңлатмалар бирү өчен авыр тормыш хәлендә калган зат чакырылырга мөмкин.

3.4. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү турында карар Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Ютазы муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге тарафыннан мөрәҗәгать итүченең шәхси эше, гаиләнең социаль паспорты һәм социаль адаптация программасы өчен тәкъдимнәр җибәрелгән көннән алып 5 эш көненнән дә соңга калмыйча ведомствоара комиссия тарафыннан кабул ителә.

3.5. Ведомствоара комиссия секретаре ведомствоара комиссия беркетмәләрен әзерли, шул исәптән Татарстан Республикасының Ютазы муниципаль районында социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме алу максатында авыр тормыш хәлендә калган затлар исемлеген 2 нөсхәдә әзерли.

3.6. Ведомствоара комиссия беркетмәсе ике нөсхәдә рәсмиләштерелә:

ведомствоара комиссия беркетмәсенең бер нөсхәсе Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Ютазы муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге тарафыннан авыр тормыш хәлендә калган затның шәхси эшенә теркәлә.

Ведомствоара комиссия беркетмәсенең икенче нөсхәсе Ютазы муниципаль районындагы авыр тормыш хәлендә калган затларга акчаларның максатчан кулланылышын тәэмин итүне оештыру өчен «Гармония» халыкка комплекслы социаль хезмәт күрсәтү үзәгенә тапшырыла.

3.7. Ведомствоара комиссия карары авыр тормыш хәлендә калган затларга законда каралган тәртиптә шикаять бирергә мөмкин.

3.8. Ведомствоара комиссия карары Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәмен билгеләү яисә кире кагу өчен нигез булып тора, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Ютазы муниципаль районындагы социаль яклау бүлегендә һәм «Гармония» халыкка комплекслы

социаль хезмәт күрсәтү үзәгендә 3 ел дәвамында сакланырга тиеш, шуннан соң ул юкка чыгарылырга тиеш.